# Ислам нуры

«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)

12+

№3 (727) 11 февраль 2021 ел (1442, Җөмәдел-ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга


*2021 ел - Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы*

## СЫНАУ ҺӘМ СЫНАЛУ



«Ул – Аллаһ үлемне һәм яшәүне сезне сынау өчен яратты. Сезнең кайсыгыз гамәле буенча иң яхшы булыр икән. Ул Җиңелмәүче, Гафу итүче Зат» (Мүлек, 2). «Без сезне начарлык һәм яхшылык белән фетнә буларак сыныйбыз һәм сез Безгә кайтарылачаксыз» (Әнбия, 35). «Без сезне чыннан да курку, ачлык, байлыкның, кешеләрнең һәм җимешләрнең кимүе белән сыначакбыз. Һәм син сынау вакытында сабыр булучыларны шатландыр» (Бәкара, 155). «Әллә кешеләр «Без иман китердек» дигәннән соң сынаусыз калдырылачаклар дип уйлыйлармы? Дөреслектә, Без инде аларга хәтле яшәгән кешеләрне дә сынадык. Аллаһ чыннан да дөрес сөйләүчеләрне һәм ялганчыларны ачыклаячак» (Гәнкәбүт, 2-3). «Әйт: «Безгә Аллаһ Тәгалә тәкъдирдә язган хәерле нәрсә генә килә. Ул безнең яклаучыбыз һәм мөэминнәр Аллаһка гына таянсыннар (ягъни ахыргы нәтиҗәне Аннан көтсеннәр» (Тәүбә, 51). Сезгә килгән бәла-казалар бары тик кулларыгыз белән кылган гөнаһларыгыз өчен генә. Һәм Ул (Аллаһ аңа карамастан) күбесен гафу итә» (Шура, 30). «Сиңа килгән теләсә кайсы хәерле нәрсә - ул Аллаһтан, ә сиңа килгән теләсә кайсы зарар синең гөнаһларың сәбәпле» (Нисә, 79). «Һәм Без Коръәннән мөэминнәргә шифа һәм рәхмәт булучы нәрсәне иңдерәбез» (Исра, 82).

*(Коръәни-Кәрим)*

## КАЗЫЙЛАР ҖЫЕЛЫШТЫ



Җөмәдел-ахир аеның 26 нчы көнендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте резиденциясендә Казыйлар шурасының чираттагы утырышы узды. Җыелыш Яшел Үзән районы имам-мөхтәсибе Габделхәмит хәзрәт Зиннәтуллин башкаруында Коръән уку һәм дога кылу белән башланды. Катнашучыларны Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев сәламләде, көн тәртибен билгеләде. Татарстан мөселманнары башлыгы Камил хәзрәт Сәмигуллин барлык казыйларның татар исемнәре сүзлеген әзерләүдә катнашулары һәм үз төбәкләрендә нәтиҗәле эшчәнлек алып барулары өчен рәхмәтләрен белдерде. 17 февральдә Татарстанның көньяк-көнбатыш төбәге казые Инсаф хәзрәт Җәләлетдиновка 45 яшь тулу, аның Тәтеш районы имам-мөхтәсибе вазифасына керешүенә 25 ел тулу уңаеннан, милләтләр һәм диннәр арасында татулыкны ныгыту, исламның асыл кыйммәтләрен үстерү һәм нәзарәт белән уңышлы хезмәттәшлек өчен аны нәзарәтнең "Бердәмлек" медале белән бүләкләде. Утырыш дәвамында казыйлар татар исемнәре сүзлеген тикшерүне төгәлләде. Китапка шәригать күзлегеннән караганда кушарга яраган, мәгънәле, матур яңгырашлы исемнәр генә кертелде. Бары гарәпчә, татарча, фарсыча, төрекчә мәгънәгә ия булган исемнәр генә калдырылды. Китап казыйлар тарафыннан тикшерелеп, бастыру өчен "Хозур" нәшриятына тәкъдим ителде. Әлеге басма Татарстанда игълан ителгән Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында дөнья күрәчәк. Аны киләчәктә һәрбер имамның өстәлендә булдыру ниятләнә. Мәчеткә балага исем куштырырга килгән һәрбер гаилә һич икеләнмичә әлеге китапта бирелгән исемнәр арасыннан күңеле якын күргәнен үз баласына куштыра алачак.

## ИЗГЕЛЕК ҖИРДӘ ЯТМАС



Спас муниципаль районында Хәйрия марафоны узды. Анда РФ Дәүләт Думасы депутаты Олег Морозов, «Алексеевскдорстрой» ААҖ директорлар советы рәисе, ТР Дәүләт Советы депутаты Фоат Вәлиев, Спас муниципаль районы башлыгы Фәргать Мөхәммәтов, район халкы һәм кунаклар катнашты. Хәйрия марафоны вакытында Фәргать Мөхәммәтов районның имам-мөхтәсибе Фәрхәт хәзрәт Минсагыйровка «Рәхмәт хаты»н һәм "2020 ел хәйриячесе" истәлекле бүләген тапшырды. Билгеле булганча, 2020 елның сентябрь уртасында Болгарда район дин әһелләре, хакимият вәкилләре катнашында «Хәйрия ярдәме үзәге» ачылды. Проектның төп максаты – мохтаҗларга ярдәм күрсәтү. Әлеге идея Спас районы мөхтәсибәте һәм Чистай епархиясенең уртак проекты нәтиҗәсендә тормышка ашты. Мохтаҗларга әйберләрне өләшү 9.00-12.00 сәгатьтә, ә кабул итү 12.00-15.00 сәгатьтә башкарыла. Район имам-мөхтәсибе Фәрхәт хәзрәт Минсагыйров сүзләренә караганда, биредә авыр тормыш хәленә яисә мохтаҗлыкка төшкән һәр кеше, диненә һәм милләтенә бәйсез рәвештә, кирәк-яраклар алып китә ала. Бирегә мөрәҗәгать итүчеләргә өс киеме, аяк киеме, урын-җир әйберләре, савыт-саба, азык-төлек – ярмалар, консервалар, көнбагыш мае, токмач тәкъдим ителә. Барлык мохтаж кешеләргә дә җитсен өчен, әйберләрне бирү исәп-хисабы алып барылачак.

*(ТР МДН хәбәрләреннән)*

# КОРӘЕШЛӘР ТӘКЪДИМЕ

**Кадерле дин кардәшләрем!**

**Пәйгамбәребез (с.г.в.) тормышына багышланган хөтбәләрне дәвам итәбез. Рәсүлебез (с.г.в.) тормышына карап, тормыш сабаклары алабыз. Бу хөтбәләрдән алган белемнәрне гади мәгълүмат яисә кызыклы вакыйга кебек кабул итәргә ярамый. Аларны үзебезгә үрнәк итеп, бу очракта Пәйгамбәребез (с.г.в.) нишләр иде, ничек хәл итәр иде бу мәсьәләне дип үзебезгә сорау бирергә тиешбез, җәмәгать.**

Аллаһы Тәгалә әйтә: «Коръәндәге кыйссаларда акыл ияләренә гыйбрәт бар».

Узган хөтбәләребездә корәешләрнең Пәйгамбәребез (с.г.в.)не һәм аның сәхәбәләрен җәберләүләренә, бик каты кыйнауларына тукталган идек. Мондый газаплар да аларны туктата алмагач, корәешләр башка юл уйлап табалар. Һәм бу юл - вәсвәсәле кылу ысулы була.

Корәешләр Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына, Әбү Бәкергә каты итеп суккан, Гутба ибн Рабига исемле кешене җибәрәләр. Алар Гутбаны җибәргәндә, аңа: «Аның белән килешергә, компромисс табарга тырыш. Ризалашсын өчен берәр төрле кызыктыргыч тәкъдим яса, бәлки ул ризалашыр», - дип җибәрәләр.

Шуннан Гутба Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына килә, каршысына утырып: «И, Мөхәммәд, безнең халык арасында нинди фетнә таратуың барча кешегә билгеле, син безнең әти-бабаларыбызны адашкан дип әйтәсең, безнең аллаларыбызны мыскыл итәсең, ә үзебезне ахмаклар дип санныйсың. Әгәр моның белән безнең мал-мөлкәтебезне алырга теләгән булсаң, бар мал-мөлкәтебезне җыеп сиңа бирербез. Хатын-кызларыбызны теләгән булсаң, без сине корәешлеләрнең иң чибәр хатын-кызына өйләндерәбез. Әгәр хакимлек кирәк икән, хакимлек бирәбез сиңа. Безнең белән идарә итәрсең. Бары тик үз динеңә чакырудан туктачы», - ди.

Игътибар итегез, аңа берсеннән-берсе кызыктыргыч, берсеннән-берсе вәсвәсәле өч тәкъдим ясала. Гади кеше вәсвәсәгә бирешергә дә мөмкин. Беренчедән, искиткеч баеп китәргә була, икенчедән, корәешләрнең иң чибәр хатынын алырга, яки бөтен Мәккәгә хуҗа булырга мөмкинлек туа. Ә алмашка нәрсә сорала? Бары тик бер нәрсә - динен калдырырга.

Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Син сөйләп бетердеңме?» - дип сорый. Тегесе: «Әйе», - дип җавап биргәч, Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Ә хәзер мине тыңла», - ди һәм «Фуссыйләт» сүрәсен укый башлый һәм Аллаһы Тәгаләнең: «Әгәр алар йөз чөерсәләр, син әйт: «Мин сезне гад һәм сәмуд халкына килгән газап шикелле бер газаптан кисәтәм».

Шушы сүзләргә җиткәч, Гутба сикереп тора да, учы белән Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең иреннәрен каплап: «Аллаһ белән ялварам, сүзеннән тукта!» - ди. Бу аятьләр аңа шулкадәр көчле аңа тәэсир итә, ул моңа түзә алмый... Корәешләр янына кайткач, аны күреп: «Аллаһ белән ант итәбез, моның йөзе үзгәргән. Аның йөзе бездән киткәндәге төсле түгел», - дип каршы алалар. Алар аннан: «Нәрсә булды?» - дип сорашырга тотыналар.

Ул: «И, халкым! Бу юлы минем сүзләремә колак салыгыз, аннан соң тыңламасагыз да бер сүз әйтмим. Бу кешенең үзен дә, аның эшен дә калдырыгыз. Ягъни Мөхәммәдне һәм аның дәгъватын калдырыгыз! Әгәр гарәп кавемнәре аны үтерә икән - бу бит сез дә теләгән нәрсә. Ә инде ул гарәпләрне үзенә буйсындырса, сезнең хакимлегегез, һәм әти-бабаларыгыз хакимлеге, ягъни аңа булган хөрмәт сезнең кавемгә дә килә.

Корәешләр: «Аллаһ белән ант итәбез, Мөхәммәд моны сихерләгән», - диләр.

Җәмәгать, Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең сүзләре нинди үтемле булган! Ничек тәэсир итә алган ул кешеләргә. Һәм игътибар итегез, һәркемгә үзенә күрә юлын, билгеле сүзләрен тапкан, шәхсән якын килгән.

Карагыз, ничек генә вәсвәсә кылмыйлар аңа! Хәтта хаким итеп куярга телиләр. Ничек уйлыйсыз, Пәйгамбәребез (с.г.в.) хакимлеккә килеп, халкын ислам динен кабул итәргә мәҗбүр итә алганмы? Әйе, мәҗбүр итә алган. Шулай булгач, ник бу тәкъдимне кабул итмәгән? Чөнки безнең динебездә «Максат - аңа ирешү чараларын аклый», ягъни «Максатка ирешү өчен теләсә нинди чара яхшы», дигән нәрсә юк. Юк, Пәйгамбәребез (с.г.в.) корәешләрнең ислам динен теләсә нинди юл белән, көчләп, мәҗбүр ителеп кабул итүләрен теләми. Максат - аңа ирешү юлларын бизәргә тиеш.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) корәешләрнең инанган мөселман булуларын, чын күңелдән ислам динен кабул итүләрен, үз куллары белән пот-сыннарын ватып ташлауларын тели.

Корәешләр җыелышып, бу дәгъватны ничек туктатырга икән дип уйлап, план төзүләрен дәвам итәләр.

Тәкъдим ителгән идеяләрнең берсе - Мәдинәдә яшәүче яһүдләргә мөрәҗәгать итәргә кирәк дигән фикер була. «Арабыздан берәү үзен пәйгамбәр дип атый, һәм аның дине генә дөрес, һәм ул бөтен диннәрнең дәвамы дип әйтә. Бәлки, сез Мөхәммәднең дәгъватына каршы торырдай нәрсә хәбәр итәрсез», - дип яһүдләр белән киңәшләшергә булалар.

Шуннан Мәдинәдә яшәүче яһүд галимнәренә делегация җибәрәләр. Яһүдләр аларга: «Аңа өч сорау бирегез. Әгәр ул бу өч сорауга җавап бирә алса, димәк, ул чыннан да пәйгамбәр, ә җавап бирә алмый икән - пәйгамбәр түгел. Теләсә нәрсә эшләтә аласыз аны», - дип әйтәләр.

«Беренче сорау: тау куышындагы егетләр турында сорагыз.

Икенчесе: көнчыгыштан көнбатышка кадәр җирләрне яулап алган бөек гаскәр башлыгы, сугышчы турында сорагыз аннан.

Өченче сорау рух турында булсын. Бу өч сорауга җавапны пәйгамбәрдән башка беркем белми».

Делегация Мәдинәдән Мәккәгә кайткач, корәешләрнең башлыклары белән очраша. Аннан Пәйгамбәребез (с.г.в.) янына барып, бу өч сорауны бирә. Шуннан тау тишегенә качкан егетләр турында аятьләр иңә. Аннан Зөл-Карнәйн турында кыйсса һәм менә бу аятьләр иңә: «Алар синнән рух (җан я Җәбраил) хакында сорыйлар. Әйт: «Рух — Раббымның әмереннән. Сезгә исә гыйлемнән аз бер өлеш кенә бирелде».

Бу җавапларның барысы да дөрес була, әмма шуңа да карамастан, корәешләр дәгъватны туктатырга кирәк дигән фикердә каты торалар.

Корәешләр бу юлларының бернинди уңыш китермәвен күреп, икенче адымга баралар. Мәккәдә исламга чакыру тарихындагы иң каты һөҗүмгә җөрьәт итәләр - Пәйгамбәребез (с.г.в.)не үтерергә карар кылалар. Бу хакта белеп алгач, бану хашим кавеме, диннәре башка булуга карамастан, Пәйгамбәребез (с.г.в.)не яклап чыгалар. Мөселман булганнары да, мөселман булмаганнары да, Пәйгамбәребез (с.г.в.) өе янына килеп басалар һәм аны куркынычсызлык астында калдыру өчен Әбү Талиб җирлегенә урнашалар. Шулай итеп, бану хашимнең бөтен кавеме Пәйгамбәребез (с.г.в.)не яклау өчен Әбү Талиб җирлегенә күченеп урнаша.

Корәешләр бәнү хашим кавеменә килеп, Пәйгамбәрне (с.г.в.) бирүләрен таләп итәләр, бәнү хашим кавеме бирүдән баш тарта. Аннан аларга Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең сәхәбәләре дә кушыла.

Бу хәлләрдән соң корәешләр башкача һөҗүм ясыйлар. Алар Әбү Талиб җирлегендә яшәүче хашимитләрне блокадага алалар. Азык-төлек һәм башка кирәк-яраклар китерергә мөмкин булган бөтен юлларны ябалар. Аннан корәешләргә: «Хашимитләр Мөхәммәдне җәзага тарту өчен безгә бирмичә торып, алар белән аралашу, өйләренә керү, теләсә нинди ярдәм күрсәтү тыела!» - дигән хат язып, аны Кәгъбәтуллаһка элеп куялар.

Бу коточкыч каты блокада өч ел дәвам итә! Җәмәгать, Мәккә шәһәре чүлдә урнашкан, берни үсми торган коры чүлдә! Аларның хәлләре шулкадәр авырлаша, хәтта агач яфрагы, хайван тиреләрен ашарга мәҗбүр булалар. Хашимитләр яшәгән яктан балаларның, хатын-кызларның ачлыктан интеккән тавышлары ишетелеп тора. Ашарга яраклы булган нәрсәләр яшерен рәвештә генә китерелә.

Әбү Талиб Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең тормышы өчен шулкадәр нык курыккан, кешеләр йокларга ятканда, үтерергә теләгән кешеләр күреп торсын өчен, аңа үзе янына ятарга кушкан, һәм барысы да йоклап киткәч, улларының берсенә Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең ятагына барып ятарга кушкан, ә аны икенче урынга качыра торган булган.

Күз алдына китереп карагыз, кардәшләрем! Бу галәмәт өч ел дәвам итә!

Өч елдан соң бу блокада белән канәгать булмаган дүрт кеше барлыкка килә. Беренчесе - Хишам бну Гамр. Икенчесе - Зухейр ибн Умайя әл-Махзуми, аның әнисе Гатика, ул Әбдулмутталибның кызы була. Өченчесе - Мутъим ибн Гади һәм дүртенче кеше - Әбу Бухтыри.

Бергә җыелып сөйләшкәннән соң алар блоканы бетерергә булалар. Харам мәчете янына барып: «Ничек сез хашимитләрне блокадалый аласыз? Без, мәсәлән, моның белән канәгать түгел. Блокада турында грамота язылганда да риза булмадык, хәзер инде бигрәк тә риза түгел», - дип корәешләргә әйтәләр.

Тавыш, гауга күтәрелә. Һәм ахырдан хашимитләргә куелган блокаданы бетерергә булалар. Блокада игълан ителүе турында язган хатларын ертып атарга дип Кәгъбәтуллаһка кергәч, шаккаталар - термитлар бу хатны ашап бетергәннәр, бары «Йә Аллаһ, Синең исемең белән» дигән сүзләр генә калган. Шулай итеп, өч ел дәвам иткән блокада бетерелә.

**Әбүбәкер хәзрәт ӘБДИЕВ,**
*Чаллының «Тәүбә» мәчете имам-хатыйбы*

# РӘГАИБ КИЧӘСЕ

Рәгаиб киче – ел саен Рәҗәб аеның беренче җомга кичәнә туры килә торган бик бәрәкәтле изге кичә. Ягъни, пәнҗешәмбе көнне кояш баегач, җомга киче керә. (Гомумән алганда, һәрбер җомга киче бәрәкәтле, яхшы кичләрдән булып санала.)

**Рәгаиб кичәсе нинди кичә?**

Бу – Пәйгамбәребезнең әтисе Габдуллаһ белән әнисе Ваһаб кызы Әминәнең никахлашкан көннәре. Быел 2021 елда бу кичә 18 февраль кичәнә туры килә. Ни өчен без Рәгаиб кичәсен билгеләп үтәбез? Чөнки шушы никах нәтиҗәсендә дөньяга рәхмәт өчен җибәрелгән Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм дөньяга килгән.

Габдуллаһтан да, Әминәдән дә алтыннар, байлыклар калмаган. Аларның никахыннан дөньяга бер изге бала туган. Бөтен никахларның максаты, нәтиҗәсе – бала. Әгәр без үзебездән соң холык ягыннан да, әхлак ягыннан да – бөтен яктан үзебезгә караганда яхшырак балалар калдырабыз икән, димәк, безнең гомеребез заяга үтмәгән, димәк, без Аллаһ Тәгалә каршысында бурычыбызны үтәгәнбез, дигән сүз. Пәйгамбәребезнең әтисе -улы туганчы, әнисе, улына алты яшь вакытта, вафат булалар. Мөхәммәд (с.г.в.) ятим кала. Әмма шушы Габдуллаһ белән Әминәнең саф җаннар, изге күңелле кешеләр, хәрамга катышмаган яхшы кешеләр булганы өчен, Аллаһ Тәгалә изге бала биреп дөньяны сөендерә.

**Ничек үткәрергә?**

Рәгаиб сүзе «рәгибә» сүзенең күплек саны, «зур кыйммәткә ия булган теләнгән әйбер, кыйммәтле бүләк, нигъмәт, сый» дигән мәгънәләргә ия. Кайбер галимнәр фикеренчә, унике рәкәгатьтән торган бу намаз шушы кичәдә Үз Илчесе салләлаһү галәйһи вә сәлләмнең йөрәгенә нур иңдергән Аллаһ Тәгаләгә шөкеранә кылу максатыннан, рәҗәб аеның беренче җомгасында укыла. Бу төнне гыйбадәттә үткәрү бик саваплы. Ләкин бу кичтә намаз укуны көчле сөннәт дияргә ышанычлы дәлилләр юк. Шуңа карамастан, галимнәр фикеренчә, изге гамәлләр кылганда көчле булмаган хәдисләргә дә таянырга мөмкин.

**Рәгаиб намазын уку тәртибе**

Әнәс ибн Мәлик китергән хәдистә: «Рәҗәб аеның беренче пәнҗешәмбесендә ураза тотарга, ә җомга төне җиткәч, кичке (ястү) һәм төнге (витр) намазлар арасында 12 рәкәгать намаз укырга кирәк. Һәр рәкәгатьтә «Фатиха» сүрәсе, өч тапкыр «Кадер» сүрәсе һәм унике тапкыр «Ихлас» сүрәсе укыла. Һәр ике рәкәгатьтән соң бер сәлам бирелә. Намазны укып бетергәннән соң 70 тапкыр салават әйтергә кирәк.

Бу намазны укучыларга Пәйгамбәребез салләлаһү галәйһи вә сәлләм шатлыклы хәбәр җиткерә: «Җаным Кемдә булса, Шуның белән ант итәм! Бу намазны укучы ир һәм хатын-кызларга Аллаһ Тәгалә бар гөнаһларын, хәтта алар диңгездәге күбек, сахрадагы ком бөртеге, яңгырдагы тамчылар, агачлардагы яфраклар кебек күп булса да, яки алар бөтен бу таулар кебек авыр булса да, гафу итәр. Кыямәт көнендә бу кеше туганнары арасыннан 700 кешегә шәфәгать итә алачак. Күмелгәч, каберенә беренче көнне үк бу намазның савабы килер һәм: «Кардәшем! Сөенә аласың, син барлык газаплардан азат ителдең!» – дияр. Кеше: «Син кем? Аллаһ белән ант итәм, мин синнән дә матуррак, мондый ягымлы тавышлы һәм хуш исле беркемне күргәнем юк», – дияр. Ул кешегә: «Сөекле дустым! Мин – фәлән елда, фәлән айда, фәлән көндә кылган намазыңның савабы. Мин сине теләгән җиреңә алып барыр өчен, бу ялгызлыгыңны уртаклашыр өчен юлдашың булырга һәм ялгызлыктан коткарырга килдем. Сурга өрелгәч, Мәхшәр мәйданында мин сиңа күләгә булып торырмын. Хәзердән сөенә аласың, чөнки шушы мизгелдән алып мәңгегәчә Аллаһың насыйп иткән бер генә нигъмәтне дә югалтмассың», – дип җавап кайтарыр». (Габделкадир Әл-Гeләни, Әл-Гунья, 1/330-331; Хафиз Мөхәммәд ибн Насыйр, Гамәли ибнел-Мәҗлис №14; Разин ибн Мугавия, Тәҗридус-Сихах; Ибн Саләх, Әл-Мусаҗәлә Хәүлә Саләтир-Рәгаиб, 14-15 б.; Ибнел-Әсир, Җәмигуль-Усуль, №4268, 6/154; Имам Газәли, Ихъя Гөлүмүд-Дин, 1/237-238; Зәбиди, Итхәфус Сәгадә, 3/422-423; Әбү Габдуллаһ Әл-убәйши, Китабүл-Бәракә, №2856, 718 б.)

Билгеле булганча, тәравих, истиска, ай һәм кояш тотылганда укыла торган нәфел намазлардан кала, нәфел намазларын җәмәгать белән уку Пәйгамбәребез салләлаһү галәйһи вә сәлләм даими рәвештә тоткан сөннәт түгел. Моннан чыгып, рәгаиб намазын азан һәм камәт әйтеп, җәмәгать белән уку бидгать булып тора. Шулай да фикһ белгечләре рәгаиб намазын 3-5 кешедән торган җәмәгать белән, азан һәм камәт әйтми генә укуны рөхсәт ителә, дип санаганнар. Кайбер факиһлар нәфел намазларны зур җәмәгать белән укуны да рөхсәт иткәннәр.

*(Камил хәзрәт Сәмигуллинның «1500 вопросов о намазе» китабыннан)*

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

# ТАЯНУ НОКТАСЫ



Сынаулар килгәндә сыгылып төшмәс өчен көчне каян алырга, нәрсә таяну ноктасы була ала - шул хакта Чаллы шәһәренең имам-мөхтәсибе **Әлфәс хәзрәт ГАЙФУЛЛИН** белән сөйләшәбез.

*- Әлфәс хәзрәт, үзегезнең дә игътибар иткәнегез бардыр, кешеләр белән сөйләшкәндә, күпләр авызыннан: “Мәнә мин Аллаһка ышанам, гөнаһ кылмыйм, урлашмыйм, шулай да бәла-казадан башым чыкмый”, - дип зарлануны ишетергә туры килә. Нинди хикмәт икән бу дип аптырыйлар...*

- Андый сорауны, чыннан да, бик күп бирәләр. Әмма шунысы да бар: мәнә кеше “Аллаһы Тәгаләгә ышанам”, - ди. Иман китерә торган әйберләр бар, без 6 әйбергә иман китерәбез: Аллаһка, Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәрләренә, аның фәрештәләренә, аның китапларына, тәкъдирнең яманы да, яхшысы да Аллаһтан икәнлегенә һәм ахирәт көненә. Әгәр тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһы Тәгаләдән дигәнгә иман китерә икән, ул вакытта кеше үз алдына “ни өчен миңа бәла килә икән” дигән сорау куймый инде. Адәм баласының төрлесе бар бит. Кемдер уйлый: “Мәнә, намазга баскач, инде иманга килгәч, бөтенесе дә тәртиптә булачак”, - ди. Иман юлында булмаганнарга Аллаһы Тәгалә күбрәк бәла бирә дип уйлаучылар да бар. Без беләбез: Аллаһы Тәгалә үзенең яраткан, иманлы бәндәләренә сынауны күбрәк бирә, күбрәк авырлыклар җибәрә. Шул рәвешле иманны, ихласны һаман да сыный. Кешеләр шуны аңласалар, килгән авырлыкларга бүтән төрле карарлар иде. Пәйгамбәребез (с.г.в.), Аллаһы Тәгалә үзенең яраткан бәндәләренә авырлыкны күбрәк бирә дигәч, хәтта кайбер сәхәбәләр, үзләренә авырлык килми башлагач: “Раббым, безне онытты бугай”, - дип, кулларын күтәреп Аллаһтан сорый торган булганнар. Без сынау дөньясында яшибез. Аллаһы сөбеханә Тәгалә безләргә сынауны кайчагында каза рәвешендә дә җибәрә. Күп чирләр, бәла-казалар барча халык өстенә дә килә. Шулай гомуми сынавы аша Аллаһы Тәгалә үзенең көчен, кодрәтен күрсәтә, барлыгын күрсәтә. Кешеләргә шуның аша хакыйкатьне аңласыннар өчен юл күрсәтә. Кеше авырлыкка очрагач, күп вакытта Аллаһны искә төшерә.

*- Авырлык килгәндә иң беренче чиратта нәрсә таләп ителә соң?*

- Сабырлык. Мәчеткә килеп, “Ник Аллаһ миңа шундый күп бәла бирә, нишләргә?” - дип сорау бирүчеләр бар. Әйтик, кемнеңдер якыны үлгән, баласы үлгән... Без шушындый авырлыкларга сабыр итә алабыз микән - Аллаһ сабырлыкны сыный. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйткән бит, сабырлар җәннәткә керерләр, дип. Без, нинди генә авырлык килмәсен, “иннәә лилләһи вә иннәә иләйһи раажигуун” дибез. Ягъни, Аллаһтан килдек һәм Аллаһка кайтабыз. Аллаһка үзебезнең иманыбыз, ихласыбыз белән ышанабыз һәм килгән казаларга сабыр итәбез. Шуның белән әҗерле булабыз. Чөнки пәйгамбәребез дә әйткән: мөселманның аның тормышы гаҗәеп, дигән: әгәр дә аңа нинди дә булса авырлык килсә, сабыр итә, шуның белән әҗерле була; ниндидер бер яхшылык килсә, Аллаһы Тәгалагә шөкер итә, аның белән шулай ук әҗерле була, ди.

*- Былтырдан бирле бөтен дөнья халкы коронавирус афәте белән көрәшә. Кемдер авырып терелде, кемдер якыннарын югалтты, кемдер, “авырмасам ярар иде”, дип дер калтырап яши. Гомумән, апатиягә, депрессиягә бирелүчеләр күзгә күренеп арта. Күңел тынгысызлыгы үзе бер авыруга әйләнеп бара шикелле.*

- Һәр эшнең үз остасы бар, әлбәттә. Кеше авыру икән, табибларга, психологларга мөрәҗәгать итә. Мөселманның иң зур коралы - дога һәм Коръән. Аллаһтан сорап дога кылганда, күбрәк Коръән укыганда, хәлне җиңеләйтми калмый. Аллаһы Тәгалә әйтә бит, Коръән - шифа, ди. Кеше бит үлемне бик ерак итеп күрә, шуның белән алдана. Әмма кайчан китәсен, нинди сәбәп белән китәсен беркем дә белми. Мөселман кешесе бүген соңгы намазымны кылам дип намаз укый, мәңге яшим дип дөнья көтә. Иртән уянуга, шөкер итеп, әлхәмдүлилаһ дип, күңелдәге иманны таяну ноктасы дип санап яшәү кирәк. Шул чагында күңел тынгысызлыгына да сәбәп булмас.

Әңгәмәдәш - **Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА**

# Март аена намаз вакытлары

| Милади март | Көн исеме | Рәҗәб, шәгъбан | Иртәнге намаз | | | | | | Кояш чыга | | | Зәвәл | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ястү | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Таң беленә | | | Мәчетләрдә укыла | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Дш | 17 | 06:06 | 04:18 | 04:31 | 06:39 | 04:51 | 05:04 | 08:06 | 06:21 | 06:34 | 13:28 | 11:42 | 11:55 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:55 | 15:07 | 15:20 | 18:52 | 17:05 | 17:18 | 20:22 | 18:46 | 18:59 |
| 2 | Сш | 18 | 06:03 | 04:16 | 04:29 | 06:35 | 04:48 | 05:01 | 08:03 | 06:18 | 06:31 | 13:28 | 11:42 | 11:55 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:57 | 15:09 | 15:22 | 18:54 | 17:07 | 17:20 | 20:24 | 18:48 | 19:01 |
| 3 | Чш | 19 | 06:01 | 04:13 | 04:26 | 06:34 | 04:46 | 04:59 | 08:01 | 06:16 | 06:29 | 13:28 | 11:42 | 11:55 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 16:59 | 15:11 | 15:24 | 18:56 | 17:09 | 17:22 | 20:26 | 18:50 | 19:03 |
| 4 | Пҗ | 20 | 05:59 | 04:11 | 04:24 | 06:31 | 04:43 | 04:56 | 07:59 | 06:13 | 06:26 | 13:28 | 11:42 | 11:55 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:01 | 15:13 | 15:26 | 18:58 | 17:11 | 17:24 | 20:28 | 18:52 | 19:05 |
| 5 | Җм | 21 | 05:56 | 04:08 | 04:21 | 06:29 | 04:41 | 04:54 | 07:56 | 06:11 | 06:24 | 13:28 | 11:41 | 11:54 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:02 | 15:15 | 15:28 | 19:00 | 17:13 | 17:26 | 20:30 | 18:54 | 19:07 |
| 6 | Шм | 22 | 05:54 | 04:05 | 04:18 | 06:27 | 04:38 | 04:51 | 07:54 | 06:08 | 06:21 | 13:27 | 11:41 | 11:54 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:04 | 15:16 | 15:29 | 19:02 | 17:15 | 17:28 | 20:32 | 18:56 | 19:10 |
| 7 | Як | 23 | 05:51 | 04:03 | 04:16 | 06:24 | 04:36 | 04:49 | 07:51 | 06:06 | 06:19 | 13:27 | 11:41 | 11:54 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:06 | 15:18 | 15:31 | 19:04 | 17:17 | 17:30 | 20:34 | 18:59 | 19:12 |
| 8 | Дш | 24 | 05:49 | 04:00 | 04:13 | 06:22 | 04:33 | 04:46 | 07:49 | 06:03 | 06:16 | 13:27 | 11:41 | 11:54 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:08 | 15:20 | 15:33 | 19:06 | 17:19 | 17:32 | 20:36 | 19:01 | 19:14 |
| 9 | Сш | 25 | 05:46 | 03:57 | 04:10 | 06:20 | 04:31 | 04:44 | 07:46 | 06:01 | 06:14 | 13:27 | 11:40 | 11:53 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:09 | 15:22 | 15:35 | 19:08 | 17:21 | 17:34 | 20:38 | 19:03 | 19:16 |
| 10 | Чш | 26 | 05:44 | 03:54 | 04:07 | 06:18 | 04:28 | 04:41 | 07:44 | 05:58 | 06:11 | 13:26 | 11:40 | 11:53 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:11 | 15:23 | 15:36 | 19:10 | 17:23 | 17:36 | 20:40 | 19:05 | 19:18 |
| 11 | Пҗ | 27 | 05:41 | 03:52 | 04:05 | 06:14 | 04:25 | 04:39 | 07:41 | 05:55 | 06:09 | 13:26 | 11:40 | 11:53 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:13 | 15:25 | 15:38 | 19:12 | 17:25 | 17:39 | 20:42 | 19:07 | 19:20 |
| 12 | Җм | 28 | 05:39 | 03:49 | 04:02 | 06:12 | 04:23 | 04:36 | 07:39 | 05:53 | 06:06 | 13:26 | 11:40 | 11:53 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:14 | 15:27 | 15:40 | 19:14 | 17:28 | 17:41 | 20:44 | 19:09 | 19:23 |
| 13 | Шм | 29 | 05:36 | 03:46 | 03:59 | 06:09 | 04:20 | 04:33 | 07:36 | 05:50 | 06:03 | 13:26 | 11:39 | 11:52 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:16 | 15:29 | 15:42 | 19:16 | 17:30 | 17:43 | 20:46 | 19:12 | 19:25 |
| 14 | Як | 1 | 05:34 | 03:43 | 03:56 | 06:07 | 04:18 | 04:31 | 07:34 | 05:48 | 06:01 | 13:25 | 11:39 | 11:52 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:17 | 15:30 | 15:43 | 19:18 | 17:32 | 17:45 | 20:48 | 19:14 | 19:27 |
| 15 | Дш | 2 | 05:31 | 03:40 | 03:53 | 06:04 | 04:15 | 04:28 | 07:31 | 05:45 | 05:58 | 13:25 | 11:39 | 11:52 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:19 | 15:32 | 15:45 | 19:20 | 17:34 | 17:47 | 20:50 | 19:16 | 19:29 |
| 16 | Сш | 3 | 05:29 | 03:37 | 03:50 | 06:02 | 04:12 | 04:26 | 07:29 | 05:42 | 05:56 | 13:25 | 11:39 | 11:52 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:21 | 15:34 | 15:47 | 19:22 | 17:36 | 17:49 | 20:52 | 19:18 | 19:32 |
| 17 | Чш | 4 | 05:26 | 03:34 | 03:47 | 05:59 | 04:10 | 04:23 | 07:26 | 05:40 | 05:53 | 13:24 | 11:38 | 11:51 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:22 | 15:35 | 15:48 | 19:24 | 17:38 | 17:51 | 20:54 | 19:21 | 19:34 |
| 18 | Пҗ | 5 | 05:24 | 03:31 | 03:44 | 05:57 | 04:07 | 04:20 | 07:24 | 05:37 | 05:50 | 13:24 | 11:38 | 11:51 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:24 | 15:37 | 15:50 | 19:26 | 17:40 | 17:53 | 20:56 | 19:23 | 19:36 |
| 19 | Җм | 6 | 05:21 | 03:28 | 03:41 | 05:54 | 04:05 | 04:18 | 07:21 | 05:35 | 05:48 | 13:24 | 11:38 | 11:51 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:25 | 15:38 | 15:52 | 19:28 | 17:42 | 17:55 | 20:58 | 19:25 | 19:38 |
| 20 | Шм | 7 | 05:19 | 03:25 | 03:38 | 05:52 | 04:02 | 04:15 | 07:19 | 05:32 | 05:45 | 13:24 | 11:37 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:27 | 15:40 | 15:53 | 19:30 | 17:44 | 17:57 | 21:00 | 19:27 | 19:41 |
| 21 | Як | 8 | 05:16 | 03:22 | 03:35 | 05:49 | 03:59 | 04:12 | 07:16 | 05:29 | 05:42 | 13:23 | 11:37 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:29 | 15:42 | 15:55 | 19:32 | 17:46 | 17:59 | 21:02 | 19:30 | 19:43 |
| 22 | Дш | 9 | 05:13 | 03:19 | 03:32 | 05:46 | 03:57 | 04:10 | 07:13 | 05:27 | 05:40 | 13:23 | 11:37 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:30 | 15:43 | 15:56 | 19:34 | 17:48 | 18:01 | 21:04 | 19:32 | 19:45 |
| 23 | Сш | 10 | 05:11 | 03:16 | 03:29 | 05:44 | 03:54 | 04:07 | 07:11 | 05:24 | 05:37 | 13:23 | 11:36 | 11:50 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:32 | 15:45 | 15:58 | 19:36 | 17:50 | 18:03 | 21:06 | 19:35 | 19:48 |
| 24 | Чш | 11 | 05:08 | 03:13 | 03:26 | 05:41 | 03:52 | 04:05 | 07:08 | 05:22 | 05:35 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:33 | 15:46 | 16:00 | 19:37 | 17:52 | 18:05 | 21:07 | 19:37 | 19:50 |
| 25 | Пҗ | 12 | 05:06 | 03:10 | 03:23 | 05:39 | 03:49 | 04:02 | 07:06 | 05:19 | 05:32 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:35 | 15:48 | 16:01 | 19:39 | 17:54 | 18:07 | 21:09 | 19:39 | 19:53 |
| 26 | Җм | 13 | 05:03 | 03:06 | 03:19 | 05:36 | 03:46 | 03:59 | 07:03 | 05:16 | 05:29 | 13:22 | 11:36 | 11:49 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:36 | 15:50 | 16:03 | 19:41 | 17:56 | 18:09 | 21:11 | 19:42 | 19:55 |
| 27 | Шм | 14 | 05:01 | 03:03 | 03:16 | 05:34 | 03:44 | 03:57 | 07:01 | 05:14 | 05:27 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:38 | 15:51 | 16:04 | 19:43 | 17:58 | 18:11 | 21:13 | 19:44 | 19:58 |
| 28 | Як | 15 | 04:58 | 03:00 | 03:13 | 05:31 | 03:41 | 03:54 | 06:58 | 05:11 | 05:24 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:39 | 15:53 | 16:06 | 19:45 | 18:00 | 18:13 | 21:15 | 19:47 | 20:00 |
| 29 | Дш | 16 | 04:56 | 02:57 | 03:09 | 05:29 | 03:39 | 03:52 | 06:56 | 05:09 | 05:22 | 13:21 | 11:35 | 11:48 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:41 | 15:54 | 16:07 | 19:47 | 18:02 | 18:15 | 21:17 | 19:49 | 20:02 |
| 30 | Сш | 17 | 04:53 | 02:53 | 03:06 | 05:26 | 03:36 | 03:49 | 06:53 | 05:06 | 05:19 | 13:21 | 11:34 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:42 | 15:56 | 16:09 | 19:49 | 18:04 | 18:17 | 21:19 | 19:52 | 20:05 |
| 31 | Чш | 18 | 04:51 | 02:50 | 03:03 | 05:24 | 03:33 | 03:46 | 06:51 | 05:03 | 05:16 | 13:20 | 11:34 | 11:47 | 14:00 | 12:00 | 12:00 | 17:43 | 15:57 | 16:10 | 19:51 | 18:06 | 18:19 | 21:21 | 19:54 | 20:08 |


*Балалар өчен*

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## ТАТАР ӘЛИФБАСЫ



Гөләндә күрше әбинең
Җимеш пешкән чиядәй.
Алдым каптым, борыч икән,
Телне өтте, ай-яй-яй!
Аңладым шунда, урлашу –
Нәни булса да, гөнаһ.
Кисәтте мине шул "чия" –
Гөнаһым кабатланмас!




Дәфтәремә хәрефләрне
Язам сәйләндәй тезеп.
"Биш"ле куйгач үзләренә,
Һәр бите тора көлеп.

Гарәпчә язуларны да
Өйрәнергә җыенам.
Аллаһ рәхмәтен бирсәме -
Барысын да булдырам!

*Саулыгым-байлыгым*

## ФАЙДАЛЫ КАТНАШМА



Кышын организм "арый", аңа витаминнар җитми, еш кына салкын тиюләр башлана. Кыйммәтле даруларның ярдәм итәсенә дә ышаныч аз. Бу очракта организмны, иммунитетны ныгыту өчен өй шартларында әзерләнгән катнашма булыша ала. Моның өчен кирәкле әйберләр: 1/2 стакан йөзем; 1 стакан әстерхан чикләвеге; 0,5 стакан миндаль (яки кедр чикләвеге); 2 лимон тышы; 150 г бал; 0,5 стакан курагә; 0,5 стакан кара җимеш. Йөзем, чикләвекләрне, лимон тышын иттарткыч аша чыгарабыз. Калган кипкән җимешләрне кушабыз. Караңгы урынга куеп 1-2 көнгә калдырыгыз. Аннан суыткычта саклагыз. Олыларга көненә 3 тапкыр 1-2 аш кашыгы, 3 яшьтән олырак балаларга көненә 2 тапкыр 1 бал кашыгы ашарга кирәк.

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР
Баш мөхәррир
Муллагалиева А. Г.
Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45
* * *
Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.

Электрон хатлар өчен:
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

Айга ике мәртәбә чыга.

Бу санның тиражы: 850
Индексы 54149

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп, динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир, типография һәм редакция адресы:
423802, Яр Чаллы,
Үзәк урамы, 72

Басарга кул куелды:
график буенча
11 февраль 16 сәг.
фактта 11 февраль 16 сәг.
Бәясе ирекле